## ТӨЗҮЧЕДӘН

...Идел кебек киң, мул сулы елгаларның да чишмә башы була.

Урманлы тау итәгеннән, йә булмаса, тигезлектән бәреп чыккан кечкенә генә инешләр, челтер-челтер агып, юлында очраган башка инешләр белән кушылалар һәм зур елга хасил итәләр.

Бары тик чишмә башын гына томалап, күмеп куймасыннар.

Иҗатта да нәкъ шулай: һәр шагыйрьнең, һәр язучының чишмә башы бар. Кемнеңдер кизләве көчле, суы мул, чиста. Ә кемнекедер йөрәк тибеше сыман салмак, акрын, аның челтерәвен таң алдыннан, сандугачлар сайраганда гына ишетергә мөмкин...

Бу җыентыкка тупланган әсәрләр нәкъ менә шул чишмә башын – кизләүне хәтерләтә. Алар төрле: җитлеккән әдипнеке дип карарга мөмкин булганнары да бар, киләчәктә күп тырышлык һәм тәҗрибә таләп иткәннәре дә юк түгел. Ничек кенә булмасын, аларга «татар әдәбияты» дигән зур, мул сулы елгага агып төшәр өчен юл ачык.

Әсәрләрне укыганда, мин шундый үзенчәлеккә игътибар иттем: яшьлек яңалык таләп итә. Традицион шигырь калыплары, ритм-рифма, күнегелгән сюжет һәм композиция элементлары хәзерге яшьләрне канәгатьләндерми. Әйтик, бөтен дөнья халкы япон шигърияте белән «җенләнгәндә», татар яшьләре генә читтә кала алмый инде, әлбәттә. Аларны *танка, ханка, хокку, сэдока* һәм башка шундый милли җирлеккә ят булган жанр төрләре кызыксындыра, алар үзебез күнеккән гадәти ритм-рифманы түгел, ә *макуракотоба* төрләрен үз итәләр... Без шундый инде: читтәге кояш ягымлырак кебек тоела. Хәсән Туфан «Иртәләр җитте исә...» шигырен иҗат иткәндә, искитәрлек камил *какэ-*

*котоба* алымы белән язганын үзе дә белми калгандыр, мөгаен...

Булсын. Болары да булсын. Чишмә агымын томаларга ярамый. Чишмәләрсез калсак, елгабыз корыр. Тора-бара чишмә үз-үзен чистарта ул.

Яшьләр ни турында яза соң? Һади Такташ унбиш яшендә «Газраилләр» шигырен язган, ә унҗиде яшендә «Күктән сөрелгәннәр» һәм «Үтерелгән пәйгамбәр»не иҗат иткән. Без яшьләрдән шундый югарылык таләп итә алабызмы? Юк. Шигырьне, гомумән, таләп итеп, мәҗбүри яздырып булмый. Хикәяне дә, пьесаны да. Моны бары тик шагыйрьнең үз күңеле генә таләп итә ала. Иҗат күңел таләбе булырга тиеш.

Яшьләр мәхәббәт турында язалар. Еш кына хикәяләрдәге мәхәббәт фаҗигале була, тезмә жанрда – сагышлы. Шигырьләргә иҗади ялгызлык кереп оялаган:

Синең кайгы-сагышларың
Кемгә кирәк?
Авыр чакларыңда кем соң
Булыр терәк?
...Алырга тырыша һәркем
Синнән файда.
Соң бу «дуслар» авыр чакта
Булды кайда?!

*(И. Галиәкбәрова)*

Яшь күңел прагматиклар заманында яшәгәнен бик яхшы аңлый, үзенең башкалардан аерылып торганлыгын күрә, тик барыбер әле аның сораулары самими, ихлас...

Прозадагы фаҗига телевизордан бик яратып күрсәтелә торган сериаллар белән килеп кергәндер, мөгаен. Яшь кеше – өйрәнчек, ул яшәргә өйрәнә. Экранда ни күрсә, шуны, садә күңеле аша кичереп, кәгазьгә төшерә...

*«Миләүшә ачуыннан кызарып чыкты, күзләрендә нәфрәт уты кабынды, һәм, һич көтмәгәндә, кулындагы пычагы белән Гөлназның йөзенә кизәнде. Бары бер хәрәкәт һәм Гөлназ битенең мең кисәккә бүлгә-*

*ләнгәндәй авыртуын, әрнүен сизде. Үзәк өзгеч авырту һәм кан». (А. Абдрахманова)*

Мондый хикәяләр күпчелек яшь язучының иҗатында күренеп ала. Бу каләм чарлау гына түгел, бу – хисләрне чарлау, күңелне иҗатка әзерләү, үзенә күрә бер ритуал... Айгөл Абдрахманова хикәяләрендә тел матурлыгы бар, сүз уйнату көчле. Өметле яшь язучы.

Ә шулай да нинди соң алар – яшьләр? Аңлап кара син аларны!

Нокта. Нокта. Җәя.
Булды, әзер.
Мин бүгенгә шундый
булырмын.

*(Л. Хәбибуллина)*

«Нокта. Нокта. Җәя»нең «смайлик» – елмаю икәнен аңлау өчен яшьләр дөньясында кайнарга кирәк. Аларча уйларга, алар белгәнне белергә, дөньяны аларча күрергә... Юкса шигырьдәге кайбер сүзләр аңлашылмаска да мөмкин:

Күңелемнең утларын сүндереп кабыздым.
«Loading» янәдән балкыды.

*(Л. Хәбибуллина)*

Компьютер дөньясы бу... Тормышны, хисләрне «йөкләтеп» алу, копиясен булдыру.

Күз төсенә кердем кебек:
Мин – сары...

*(Р. Габдрахманова)*

«Сары мин» сары күздә эреп югалмасмы? Автор үзе дә мондый мөмкинлек турында уйлана. Бертөрлелек, «сорылык дөньясы»нда шагыйрьнең урыны кайда? «Шәһәр таңга битараф» шигырен мин һич кенә дә битараф күңел белән укый алмыйм...

Шәһәр таңга битараф... Аңа нәрсә?
Кояш чыгар кабат, яңа көн булыр.
Кеше агымын соры пәрдә сарган.
Инсаниятә мөһер:
«Күзле сукыр!»
<...> Мин дә бүген соры плащ кидем өскә –
Әйе, агым чәйнәп йотты яңадан.

Йөземә элгән төссез битлеккә генә
Ихлас елмаю сурәте ясалган.

*(Р. Габдрахманова)*

Сискәндерә торган шигырь. «Күзле сукыр»лар агымының шагыйрьне «чәйнәп йотуы» белән күңел килешми...

Яшьләр ничек сөйләшәләр?

Күпсүзлелек хәзер модада түгел. Игътибар итсәгез, хәтта туган көн белән котлаганда да, яшьләр кочак-кочак теләк теләмиләр, үзләренең хисләрен бер җөмләгә, кайчак бер сүзгә сыйдыралар: «Котлыйм!» Күпсүзлелек алар дөньясында төчеләнү – «ванильлек» дип кабул ителә. Кыскалыкта – осталык.

**Үпкәләшү**

Ярату. Сөю. Бәхет.
Күк каты. Хыял. Тәхет.
Сүз. Караш. Тынлык. Яра.
Авыр таш. Газап. Ара.

*(Г. Яппарова)*

Болар аерым сүзләр генә түгел, болар – җөмләләр. Атау җөмләләр. Һәрберсенә тау кадәр мәгънә яшеренгән. Үзеннән-үзе Александр Блокның «Ночь. Улица. Фонарь. Аптека» шигыре искә төшә... Татар шигъриятенә дә мондый алым ят түгел.

Кайчакта шигырьләрдәге абстракциялелек шулкадәр югары ноктага җитә ки, укучы авторның фикер сөрешен югалта, шигырь мәгънәсен кайдадыр иксез-чиксез галәм киңлегендә Бөек Акыл белән Мәңгелек Хис бәрелешкән урыннан эзләп утырырга мәҗбүр була. Бу – мавыгу. Үтә. Бераздан яшь автор, үзе дә сизмәстән, Гамил Афзал садәлегенә кайтып төшә, безне уратып алган дөнья аңа никадәр генә катлаулы тоелса да, бөеклекнең гадилектә икәнен аңлый.

Соңгы вакытта яшьләр арасында драматургия жанрына да игътибар артты. Җыентыкта бу юнәлешне бары тик Чулпан Гобәйдуллина иҗатында гына күрә алабыз. Чулпан хикәяләр, шигырьләр дә яза, әмма «Әллүки»гә ул нәкъ менә яшь драматург булып килеп

керде. Драматург булыр өчен, тел белән әдәбиятны гына түгел, ә сәхнә культурасын, артистлар дөньясын да белергә кирәк. Драма әсәре язылган вакытта ук инде сәхнәдә уйналачак әсәр итеп күзалланырга тиеш, аның төп коралы – хәрәкәт. Хәрәкәтне оештыру бик авыр шөгыль, шуңа күрә яшьләр арасында гына түгел, гомумән, татар язучылары арасында да драматурглар бармак белән санарлык. Чулпанның осталыгы диалоглар коруда, хәрәкәтне җанлы итеп бирүдә чагыла.

Иҗатта тел мәсьәләсе бик кискен куела. Әлбәттә, баш әйләнерлек, акыл ирешмәслек троплар кулланып кына телнең сәнгатьчә югарылыгын, матурлыгын тәэмин итеп булмый. Хәер, яшь буын сурәтләү чараларын яратып бетерми. Гасырлар буе татар әдәбияты үсешенә йогынты ясаган көнчыгыш поэзиясе һәм сурәтләү системасы артка чигенде, бүгенге әдәбиятта көнбатыш мәдәнияте, көнбатыш прагматиклыгы өстенлек итә. Әмма Галимҗан Ибраһимов, Әмирхан Еники, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Фатих Хөсниләрнең тел үрнәген саклап каласы иде. Сурәтле әдәби тел һәрвакыт заман таләбе булырга тиеш.

«Әллүки»нең иң авырткан урыны – иҗатка ир-егетләрнең аз килүе. Бу – тулаем татар әдәбиятына хас күренеш. Ир балаларның бик сирәге генә китап укып үсә. Укучысы булмаган әдәбиятның язучысы да юк. Нишлисең, әлегә шундый заман, ләкин ул киләчәктә барыбер бер үзгәрер. Җыентыкта Алмаз Мансуровның шигырьләре урын алган. Ул шулай ук проза өлкәсендә дә каләм чарлый, публицистикада да актив. Кайчандыр «Әллүки»дә канат чыгарган Ленар Шәех, Рөстәм Галиуллин, Булат Ибраһим кебек. Шунысы шатландыра: берәм-берәм булса да, берәгәйле шул ир-егетләребез...

...Кайчандыр мин «Иҗат ул – дөнья белән сөйләшү» дип язган идем. «Әллүкиче»ләрнең иҗатында, чыннан да, дөнья белән сөйләшү бар. Алар үзгәреп торган әйләнә-тирәдә үз-үзләрен табарга тырышалар, өметләнәләр, максатлар һәм маяклар билгелиләр. Шу-